РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**№ 26** **« 18 » августа 2016 г.**

Теләче муниципаль районының Әтиләр иҗтимагый Советын төзү турында

Гаиләләрнең рухи – әхлакый потенциалын саклап калу һәм үстерү, әти статусына хөрмәт тәрбияләү, балаларны тәрбияләү өчен ата-аналарның җаваплылыгын арттыру, гаилә әгъзаларының иҗади сәләтенә ярдәм итү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә дәүләт гаилә сәясәте концепциясен раслау турында»2014 елның 25 августындагы 1618-р номерлы боерыгын тормышка ашыру кысаларында.

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Теләче муниципаль районының Әтиләр иҗтимагый Советын төзергә.
2. Теләче муниципаль районының Әтиләр иҗтимагый Советы турында Нигезләмәне 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.
3. Теләче муниципаль районының Әтиләр иҗтимагый Советы составын 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Р. Шәйдуллинга йөкләргә.

И. Ф. Зарипов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕГЕ

Теләче муниципаль район Башлыгының
«18» август 2016 ел № 26 карарына
1 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районының Әтиләр иҗтимагый Советы турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әтиләр Иҗтимагый советы (алга таба - совет) Теләче муниципаль районының иҗтимагый ата-аналар органы булып тора.

1.2. Әлеге Нигезләмә Советны оештыруның вәкаләтләрен, максатларын, бурычларын, функцияләрен, тәртибен билгели.

1.3. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенә, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, муниципаль норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

1.5. Совет түбәндәге максатларда оештырыла:

1.5.1. Әтиләрнең гаилә институтын һәм гаилә яшәү рәвешен ныгытуда, үсеп килүче буында рухи һәм мәдәни кыйммәтләрне үстерүдә көчләрен берләштерү;

1.5.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында җаваплы ата-анага һәм балаларның конституциячел хокукларына ярдәм итү буенча гомуми стратегияне һәм дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру;

1.5.3. Җәмгыятьтә гаилә ролен ныгытуда, ана булуны, ата булуны, балачакны саклауда, ир-атларның һәм хатын-кызларның репродуктив хокукларын тормышка ашыру өчен шартлар тәэмин итүдә ата-аналарның тырышлыгын һәм килешеп эшләүләрен тәэмин итү.

## 2. Советның төп бурычлары

2.1. Советның төп бурычлары булып тора:

2.1.1. гаилә һәм балачак институтларын ныгыту һәм үстерү мәсьәләләрендә ир-атларның эшчәнлеген активлаштыру;

2.1.2. үз компетенциясе кысаларында гаилә сәясәте өлкәсендә оештыру, тәрбия һәм башка чаралар эшләүдә катнашу;

2.1.3. гаилә кыйммәтләрен саклау, девиант тәртипне профилактикалау мәнфәгатьләрендә җәмәгатьчелек фикерен формалаштыруда катнашу;

2.1.4. гаилә тәрбиясе буенча уңай тәҗрибәне пропагандалый, ата-аналарның балаларны тәрбияләү өчен җаваплылыгын арттыра.

**3.**

## 4. Советның функцияләре

3.1. Ата булу, җаваплы ата булу, гаилә һәм балалар мәсьәләләре буенча планнар, программалар әзерләүдә катнаша.

3.2. Гаилә сәясәте мәсьәләләре буенча киңәшмәләр, семинарлар һәм башка чаралар әзерләүдә һәм үткәрүдә катнаша.

3.3. Профилактик рейд чараларын үткәрүдә катнаша.

3.4. Халыкка гаилә, ата булу, ана булу һәм балачак мәнфәгатьләрендә үткәрелә торган сәясәт турында тулырак мәгълүмат җиткерү максатыннан массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә.

3.5. Массакүләм сәламәтләндерү, мәдәни, спорт чаралары, авыр тормыш шартларына дучар булган гаиләләргә, "хәтәр төркеме" гаиләләренә ярдәм итү буенча социаль акцияләр оештыра.

3.6. Гаиләгә социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен хәл итүдә район берләшмәләре белән хезмәттәшлек итә.

## 3. Совет эшчәнлеген оештыру

4.1. Совет составы Теләче муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

4.2. Совет эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне Совет рәисе башкара, ул:

- Советның эш планын раслый
- Совет әгъзалары арасында функциональ вазыйфаларны бүлә;
- Башкарма комитет Җитәкчесенә Совет составына кертү яки аннан аерым әгъзаларны төшереп калдыру турында тәкъдимнәр кертә;
- Совет утырышларын үткәрә.

4.3. Совет Рәисенең урынбасары бар, ул Совет рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен башкара.

4.4. Совет утырышлары кирәк булган саен үткәрелә, әмма кварталга кимендә бер тапкыр, һәм әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Совет утырышларында аның эшчәнлеген яктырту максатларында массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

4.5. Совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә, Совет рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан имзаланган беркетмәләр рәсмиләштерелә. Совет тарафыннан кабул ителгән карарлар тәкъдим итү характерына ия.

Теләче муниципаль район Башлыгының
«18» август 2016 ел № 26 карарына
2 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районының Әтиләр Иҗтимагый советы составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Нуртдинов Рәис Рөстәм улы | Теләче РО РОСТО (ДОСААФ) РТ башлыгы (килешү буенча). |

**Рәис урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Фазлыев Мөхәмәтданил Мөхәммәтдин улы | Алабуга бүлеге «Татэнергосбыт» ААҖ филиалының Теләче районы җитештерү участогы башлыгы. |

**Комиссия сәркатибе:**

| | |
|---|---|
| Галимҗанов Айдар Муса улы | «Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Мөбинов Илдар Вакыйф улы | Теләче МР Советы аппараты җитәкчесе; |
| Мортазин Фидаил Абдуләхәт улы | ААҖ «АК БАРС» Банк Казан филиалының өстәмә офис башлыгы; |
| Яхин Рәис Рәшит улы | Теләче МР Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Емельянов Юрий Иванович | Район Башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы; |
| Галиуллин Илсур Илгиз улы | ДАССУ "Теләче районы үзәк хастаханәсе" баш табибы (килешү буенча); |
| Арсланов Роберт Минһаҗ улы | ПО «Бердәм Россия»нең Теләче бүлекчәсе җитәкчесе. |